2021 елның 1 маеннан 20 маена кадәр техникумда 1-2 курс студентлары арасында "Халыкның Бөек Ватан сугышында батырлыгы" дигән темага иншалар һәм рәсемнәр бәйгесе үткәрелде. Бәйгене Гомәрова Г.М. һәм Кәримова А. Ф. оештырды.

Бәйгедә 60 тан артык укучы катнашты. Фаткуллин Айнур "Эссе", Мусина Зилә "Рәсем", Исмәгыйлев Илфат "Шигырь" номинациясендә җиңүчеләр булдылар.

Бәйгенең максаты – үсеп килүче буында үз Ватаннарына, якыннарына һәм дусларына мәхәббәт, ветераннарга  һәм БВ сугышында катнашучыларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

Бәйгегә йомгак ясап, яшь һәм өлкән буынның ветераннарга, халык хәтеренә сугыш турында кайгыртучан һәм сакчыл мөнәсәбәтен билгеләп үтәсе килә. Бөек Ватан сугышына багышланган иҗат бу аерым күренеш, ул Җиңү һәм тынычлык хисләре һәм югалтуларның ачы хәсрәте белән сугарылган. Сугыш кайтавазы киләчәк буыннарда җиңү һәм тынычлык тавышы белән генә яңгырасын иде.

